**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Клубная, д.1а, село Кутема, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Клуб урамы, 1а йорты, Күтәмә авылы, 423112

тел.+7(84396) 4-30-88, e-mail: Kut.Cmn2@tatar.ru

---

**№ 102** **18 декабрь 2023 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Күтәмә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы №25-ФЗ Федераль законнарга, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Кодексының 16.1 статьясына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 августындагы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» №61 карары;
- «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 августындагы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» №61 карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2021 елның 30 сентябрендәге №38 карары.

2. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга (parvo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Н.Г. Сабиров